МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21-03.2016 г.Казань № 45/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2016 елның 15 гыйнварындагы “2016 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алына торган акчалар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” № ½-пр боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 24 июнендәге “Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан агросәнәгать комплекслары объектларын төзү һәм модернизацияләү очен, шулай ук техника һәм җайланма сатып алу өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлеген каплауга субсидияләр бирү һәм бүлү тәртипләрен раслау хакында” № 624 карарын үтәү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2016 елның 15 гыйнварындагы “2016 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме очен федераль бюджеттан алына торган акчалар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” № ½-пр боерыгына (16.02.2016 № 15/2-пр боерыгы белән үзгәрешләр кертелде) (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Боерыкның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 1.12, 1.13, 1.14, 1.15 пунктчаларын өстәргә:

“1.12. 2016 елда федераль бюджет акчалары хисабыннан җимеш саклау биналарын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр бирү тәртибе (1 кушымта);

1.13. 2016 елда федераль бюджет акчалары хисабыннан бәрәңге һәм яшелчә саклау биналарын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр бирү тәртибе (2 кушымта);

1.14. 2016 елда федераль бюджет акчалары хисабыннан теплица комплексларын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр бирү тәртибе (3 кушымта);

1.15. 2016 елда федераль бюджет акчалары хисабыннан сөт юнәлешендәге терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр бирү тәртибе (4 кушымта).

2. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору буенча Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Н.Л. Титовны җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
21.03.2016 № 45/2-пр боерыгына
1 кушымта

2016 елда федераль бюджет акчалары хисабыннан җимеш саклау биналарын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр бирү
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип 2016 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала, (алга таба – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) федераль бюджет акчалары хисабыннан җимеш саклау биналарын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә, шулай ук техника һәм җайланма сатып алуга турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

Бу Кагыйдәләрдә техника һәм җайланма дигәндә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 27 декабрендәге “Авыл хуҗалыгы техникасын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында” № 1432 карары белән расланган Авыл хуҗалыгы техникасын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү кагыйдәләрендәге таләпләргә җавап бирә торган авыл хуҗалыгы техникасы аңлашыла.

2. Субсидияләрне бирүнең максаты булып Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2015 елның 24 июлендәге “Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә юнәлдерелгән инвестиция проектларын сайлап алу тәртибен раслау турында” № 318 боерыгында билгеләнгән җиләкләрне һәм җимешләрне саклау буенча куәтләр төзүгә һәм (яки) аларны модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау тора.

3. Субсидияләрне бирү Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) шушы Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга расланган бюджет йөкләмәләре чикләрендә башкарыла.

4. Җимеш саклау биналарын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр алуга карата авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен сайлап алу критерийлары:

төп эшчәнлек төре – авыл хуҗалыгында җитештерү, җимешләр һәм җиләкләр үстерү;

милекчелек хокукында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренеке булган, куәте бер тапкыр саклау очен кимендә 500 тонна, ләкин 10000 тоннадан артык булмаган, төзелгән һәм (яки) модернизацияләнгән җимеш саклау биналары булу;

милектә (яки арендада) кимендә 10 га мәйданлы бакча булу;

бакча булдыруга проект;

җимешләрне һәм җиләкләрне (культураның аталышына карап) саклау буенча кабул ителгән технологияләр нигезендә саклыкханәдә микроклимат торышын тәэмин итәторган янгын куркынычсызлыгы һәм технология системалары булу.

5. Төзелгән һәм (яки) модернизацияләнгән җимеш саклау биналары белдерелгән проект куәтеннән 100 процент күләмендә, чыгу-рөхсәт бирү документлары һәм

тоташтыруның техник шартлары расланган җылылык, энергия һәм су ресурслары белән тәэмин ителергә тиеш.

6. Арбитраж суды тарафыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә карата болгенлеккә төшү турында эш кузгатылган очракта, алар (авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) бу хакта эш кузгатылган көнне Министрлыкка хәбәр итәргә тиеш.

Субсидияләр аларга карата арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелми.

7. Субсидияләр бирелүнең нәтиҗәлелек күрсәткечләре булып төзелгән һәм модернизацияләнгән саклыкханәләрдә җимешләрне һәм җиләкләрне бер мәртәбә саклау буенча проект куәтенә ирешү тора.

8. Субсидияләр субсидия бирелгән елдан соң 2 елдан да артмаган чорда төзелә һәм (яки) модернизацияләнә башлаган саклыкханәләрне төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен, – өстәлгән бәясеннән салымын һәм проект-эзләнү эшләренә тотылган чыгымнарны алып, смета бәясеннән 20 проценты күләмендә, ләкин объектның чик күләмендәге бәясеннән артык булмаган күләмлш бирелә.

Объектның чик күләмендәге бәясе объектның куәт берәмлеге бәясенең Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы билгели торган чик күләмдәге күрсәткеченнән чыгып билгеләнә.

Турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау объектны кабул итү Акты тапшырылганнан соң башкарыла.

Техника һәм җайланма өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча федераль бюджеттан алына торган акчаларның өлеше техника һәм (яки) җайланма берәмлеге бәясенең 20 процентын тәшкил итә (ләкин объектның смета бәясенең 5 проценттыннан да артык түгел).

9. Субсидияләрне алу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

ирекле рәвештә, үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирелү турында гариза;

төзү һәм модернизацияләү буенча җыелма смета исәпләмәсенең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

проект документларының һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең дәүләт экспертизасы буенча уңай бәяләмәсенең һәм смета бәясен билгеләүнең дөреслегенә карата үткәрелгән дәүләт экспертизасының авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

объект төзелешенә бирелгән рөхсәтнең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәсе;

саклыкханәләрне төзүгә һәм моңернизацияләүгә карата подряд шартнамәләренең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ КС-2 “Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт” статистика рәвеше буенча белешмәләрнең төзелеш контрольлеген башкаручы оешма белән килештерелгән, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ КС-3 “Башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында акт” статистика рәвеше буенча белешмәләрнең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ КС-2 “Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт” статистика рәвеше буенча белешмәләрнең төзелеш контрольлеген башкаручы оешма белән килештерелгән һәм №КС-3 “Башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында акт” статистика рәвеше буенча белешмәләрнең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре, эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда;

№КС-11 “Төзелеше тәмамланган объектны кабул итү акты” статистика рәвеше буенча актларның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ ОС-1а “Бинаны (корылманы) кабул итү-тапшыру турында” һәм №ОС-3 “Үзгәртеп корылган, модернизацияләнгән төп чара объектларын кабул итү-тапшыру актлары” статистика рәвешләре буенча актларның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ОС-15 “Җайланманы монтажлауга кабул итү-тапшыру турында акт” статистика рәвеше буенча актларның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең милегендә төзелгән һәм (яки) модернизацияләнгән саклыкханәләр булуны раслый торган документларның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

субсидия бирелгән елдан соң 2 елдан иртәрәк булмаган чорда сатып алынган техниканы һәм җайланманы китерү (сату-алу) шартнамәсенең, товар кәгазенең, счет-фактураның, китертү (сату-алу) шартнамәсенә карата кабул итү-тапшыру актының, ОС-1 рәвеше буенча кабул итү-тапшыру актының авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

банк тарафыннан таныкланган, техника һәм җайланма өчен түләнәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләре;

җайланманың яисә техниканың паспорты күчермәсе (эшләнмә паспорты);

Министрлык раслаган рәвештә субсидияләр бирү өчен белешмә-исәпләмә.

10. Министрлык:

субсидияләр бирелү турында гаризаны кергән көнендә дәфтәрдә терки, ул номерланырга, тегелергә һәм мөһер белән беркетелергә тиеш;

гаризаны теркәгәннән соң 20 көнлек чорда тапшырылган документларның шушы Тәртипнең 9 пунктына туры килүе буенча тикшерә һәм субсидияне бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

Субсидия бирүдән баш тарту нигезләре:

документларны тулы күләмдә тапшырмау яки аларның шушы Тәртип таләпләренә җавап бирмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитында калдык өлеш булмау.

Субсидияләрне бирүдән баш тарткан очракта, Министрлык шушы пунктның өченче кызыл юлында күрсәтелгән чор узганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек чорда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә баш тарту турында белдерүнамә җибәрә.

Субсидия бирүдән баш тарту законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять кылынырга мөмкин.

11. Министрлык авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән Министрлык раслаган рәвештә һәм чорларда субсидияләр бирү турында килешү төзи.

12. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган

үзенең лицевой счетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең исәп-хисап счетларына, акча чараларын бирү турында карар кабул ителгәннән соң 10 эш көне эчендә, Министрлык раслаган белешмә-исәпләмәләр нигезендә, акча чараларын күчерүне хәл итә.

13. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 кон эчендә федераль бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.

14. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет керемене кире кайтарылырга тиеш.

15. Бу Тәртипнең 13 һәм 14 пунктларында күрсәтелгән бюджет акчаларын федераль бюджет керемене ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

16. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

17. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның җитәкчеләренә һәм вазифаи затларына йөкләнә.

18. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
21.03.2016 №45/2-ил боерыгына
2 кушымта

2016 елда федераль бюджет акчалары хисабыннан бәрәңге саклау (яшелчә саклау) биналарын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау
буенча субсидияләр бирү
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип 2016 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала, (алга таба – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) федераль бюджет акчалары хисабыннан бәрәңге саклау (яшелчә саклау) биналарын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә, шулай ук техника һәм җайланма сатып алуга турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

Бу Кагыйдәләрдә техника һәм җайланма дигәндә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 27 декабрендәге "Авыл хуҗалыгы техникасын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында" № 1432 карары белән расланган Авыл хуҗалыгы техникасын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү кагыйдәләрендәге таләпләргә җавап бирә торган авыл хуҗалыгы техникасы аңлашыла.

2. Субсидияләрне бирүнең максаты булып Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2015 елның 24 июлендәге "Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә юнәлдерелгән инвестиция проектларын сайлап алу тәртибен раслау турында" № 318 боерыгында билгеләнгән яшелчә һәм бәрәңге саклау буенча куәтләр төзүгә һәм (яки) аларны модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау тора.

3. Субсидияләрне бирү Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) шушы Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга расланган бюджет йөкләмәләре чикләрендә башкарыла.

4. Бәрәңге саклау (яшелчә саклау) биналарын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр алуга карата авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен сайлап алу критерийлары:

төп эшчәнлек төре – авыл хуҗалыгында җитештерү, яшелчәләр һәм (яки) бәрәңге үстерү;

милекчелек хокукында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренеке булган, куәте бер тапкыр саклау өчен кимендә 1000 тонна, ләкин 20000 тоннадан артык булмаган, төзелгән һәм (яки) модернизацияләнгән бәрәңге саклау (яшелчә саклау) биналары булу;

милектә (яки арендада) кимендә бәрәңге өчен кимендә 50 га мәйданлы бакча булу (бәрәңге саклау биналары өчен);

субсидия алган елдан соң килүче елда бәрәңге җитештерү күләме кимендә 1000 тонна (бәрәңге саклау биналары өчен);

милектә (яки арендада) кимендә яшелчә культуралары өчен кимендә 50 га мәйданлы бакча булу (яшелчә саклау биналары өчен);

субсидия алган елдан соң килүче елда яшелчә культураларын җитештерү күләме кимендә 2000 тонна (яшелчә саклау биналары өчен);

бәрәңгене һәм яшелчәне үстерү, җыю һәм заманча технологияләр буенча эшкрәтү өчен махсус машиналар һәм җайланмалар комплексына ия булу.

5. Төзелгән һәм (яки) модернизацияләнгән бәрәңге саклау биналары (яшелчә саклау биналары) түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

билдерелгән проект куәтеннән 100 процент күләмендә, чыгу-рөхсәт бирү документлары һәм тоташтыруның техник шартлары расланган җылылык, энергия һәм су ресурслары белән тәэмин ителергә тиеш;

яшелчә белән бәрәңгене саклау буенча кабул ителгән технологияләр нигезендә саклыкханәдә микроклимат торышын тәэмин итәторган янгын куркынычсызлыгы һәм технология системалары булу

6. Арбитраж суды тарафыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылган очракта, алар (авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) бу хакта эш кузгатылган көнне Министрлыкка хәбәр итәргә тиеш.

Субсидияләр аларга карата арбитраж суды тарафыннан болгенлеккә төшү турында эш кузгатылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелми.

7. Субсидияләр бирелүнең нәтиҗәлелек күрсәткечләре булып төзелгән һәм модернизацияләнгән саклыкханәләрдә береңге белән яшелчәләрне бер мәртәбә саклау буенча проект куәтенә ирешү тора.

8. Субсидияләр субсидия бирелгән елдан соң 2 елдан да артмаган чорда төзелә һәм (яки) модернизацияләнә башлаган бәрәңге саклау биналарын (яшелчә саклау биналарын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен, – өстәлгән бәясеннән салымын һәм проект-эзләнү эшләренә тотылган чыгымнарны алып, смета бәясеннән 20 проценты күләмендә, ләкин объектның чик күләмендәге бәясеннән артык булмаган күләмлш бирелә.

Объектның чик күләмендәге бәясе объектның куәт бирәмлеге бәясенең Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы билгели торган чик күләмдәге күрсәткеченнән чыгып билгеләнә.

Турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау объектны кабул итү Акты тапшырылганнан соң башкарыла.

Техника һәм җайланма өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча федераль бюджеттан алына торган акчаларның өлеше техника һәм (яки) җайланма бирәмлеге бәясенең 20 процентын тәшкил итә (ләкин объектның смета бәясенең 5 проценттыннан да артык түгел).

9. Субсидияләрне алу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

ирекле рәвештә, үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирелү турында гариза;

төзү һәм модернизацияләү буенча җыелма смета исәпләмәсенең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

проект документларының һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең дәүләт экспертизасы буенча уңай бәяләмәсенең һәм смета бәясен билгеләүнең дөреслегенә

карата үткәрелгән дәүләт экспертизасының авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

объект төзелешенә бирелгән рөхсәтнең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәсе;

саклыкханәләрне төзүгә һәм моңернизаңияләүгә карата подряд шартнамәләренең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ КС-2 "Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт" статистика рәвеше буенча белешмәләрнең төзелеш контрольлеген башкаручы оешма белән килештерелгән, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ КС-3 "Башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында акт" статистика рәвеше буенча белешмәләрнең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ КС-2 "Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт" статистика рәвеше буенча белешмәләрнең төзелеш контрольлеген башкаручы оешма белән килештерелгән һәм №КС-3 "Башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында акт" статистика рәвеше буенча белешмәләрнең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре, эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда;

№КС-11 "Төзелеше тәмамланган объектны кабул итү акты" статистика рәвеше буенча актларның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ ОС-1а "Бинаны (корылманы) кабул итү-тапшыру турында" һәм №ОС-3 "Үзгәртеп корылган, модернизацияләнгән төп чара объектларын кабул итү-тапшыру актлары" статистика рәвешләре буенча актларның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ОС-15 "Җайланманы монтажлауга кабул итү-тапшыру турында акт" статистика рәвеше буенча актларның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең милегендә төзелгән һәм (яки) модернизаңияләнгән саклыкханәләр булуны раслый торган документларның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

субсидия бирелгән елдан соң 2 елдан иртәрәк булмаган чорда сатып алынган техниканы һәм җайланманы китерү (сату-алу) шартнамәсенең, товар кәгазенең, счет-фактураның, китертү (сату-алу) шартнамәсенә карата кабул итү-тапшыру актының, ОС-1 рәвеше буенча кабул итү-тапшыру актының авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

банк тарафыннан таныкланган, техника һәм җайланма өчен түләнәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләре;

җайланманың яисә техниканың паспорты күчермәсе (эшләнмә паспорты);

Министрлык раслаган рәвештә субсидияләр бирү өчен белешмә-исәпләмә.

10. Министрлык:

субсидияләр бирелү турында гаризаны кергән көнендә дәфтәрдә терки, ул номерланырга, тегелергә һәм мөһер белән беркетелергә тиеш;

гаризаны теркәгәннән соң 20 көнлек чорда тапшырылган документларның шушы Тәртипнең 9 пунктына туры килүе буенча тикшерә һәм субсидияне бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

Субсидия бирүдән баш тарту нигезләре:
документларны тулы күләмдә тапшырмау яки аларның шушы Тәртип таләпләренә җавап бирмәве;
бюджет йөкләмәләре лимитында калдык өлеш булмау.
Субсидияләрне бирүдән баш тарткан очракта, Министрлык шушы пунктның өченче кызыл юлында күрсәтелгән чор узганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек чорда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә баш тарту турында белдерүнамә җибәрә.
Субсидия бирүдән баш тарту законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять кылынырга мөмкин.
11. Министрлык авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән Министрлык раслаган рәвештә һәм чорларда субсидияләр бирү турында килешү төзи.
12. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең исәп-хисап счетларына, акча чараларын бирү турында карар кабул ителгәннән соң 10 эш көне эчендә, Министрлык раслаган белешмә-исәпләмәләр нигезендә, акча чараларын күчерүне хәл итә.
13. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет керемена кире кайтарылырга тиеш.
14. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет керемена кире кайтарылырга тиеш.
15. Бу Тәртипнең 13 һәм 14 пунктларында күрсәтелгән бюджет акчаларын федераль бюджет керемена ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.
16. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.
17. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның җитәкчеләренә һәм вазифаи затларына йөкләнә.
18. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
21.03.2016 №45/2-пр боерыгына
3 кушымта

2016 елда федераль бюджет акчалары хисабыннан теплица комплексларын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр бирү
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип 2016 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан кала, (алга таба – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) федераль бюджет акчалары хисабыннан теплица комплексларын, шул исәптән, газпешкәк станцияләрен, когенерацияләү һәм котельный җайланмаларын да кертеп, җылылык энергетикасы үзәкләрен төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә, шулай ук техника һәм җайланма сатып алуга турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр бирү тәртибе (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

Бу Кагыйдәләрдә техника һәм җайланма дигәндә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 27 декабрендәге "Авыл хуҗалыгы техникасын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында" № 1432 карары белән расланган Авыл хуҗалыгы техникасын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү кагыйдәләрендәге таләпләргә җавап бирә торган авыл хуҗалыгы техникасы аңлашыла.

2. Субсидияләрне бирүнең максаты булып Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2015 елның 24 июлендәге "Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә юнәлдерелгән инвестиция проектларын сайлап алу тәртибен раслау турында" № 318 боерыгында билгеләнгән теплица комплекслары куәтләрен төзүгә һәм (яки) аларны модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау тора.

3. Субсидияләрне бирү Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) шушы Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга расланган бюджет йөкләмәләре чикләрендә башкарыла.

4. Теплица комплексларын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр алуга карата авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен сайлап алу критерийлары:

төп эшчәнлек төре – авыл хуҗалыгында җитештерү, яшелчәләр үстерү;

теплица комплексларының минималь мәйданы елына кимендә 3 га, ләкин 30 гектардан артмаган күләмдә булырга тиеш;

өстәмә кишәрлекләр булдырганда гамәлдәге теплица комбинатларында – елына кимендә 1 гектар, ләкин 30 гектардан артыграк түгел;

аналоглары Россиядә җитештерелми торган җайланмадан кала, үзебезнең илдә җитештерелгән конструкцияләрдән, технологик җайланмалардан һәм материаллардан җайланманың бәясенең кимендә 30 проценты күләмендә файдалану;

теплицаларның теплицаларда бер квадрат метрга кимендә 50 кг яшелчә культуралары, томатлар өчен – квадрат метрына кимендә 45 кг, салатлар өчен –

квадрат метрына кимендә 25 кг уңыш алу өчен кирәкле булган микроклимат торышын саклау һәм технология процессларын башкаруны тәэмин итүче инженерлык системалары һәм технологик җайланмалар белән тәэмин ителеше.

5. Төзелгән һәм (яки) модернизацияләнгән теплица комплекслары түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

белдерелгән проект куәтеннән 100 процент күләмендә, чыгу-рөхсәт бирү документлары һәм тоташтыруның техник шартлары расланган җылылык, энергия һәм су ресурслары белән тәэмин ителергә тиеш;

модернизацияләнергә тиешле кишәрлектә уңыш алуны һәм/яки еллык җитештерү күләмен кимендә 30 процентка арттырырга мөмкинлек бирә торган технологик җайланма, шулай ук газпешкәк станцияләрен, когенерацияләү һәм котельный җайланмаларын исәпкә алып, өстәмә җылылык энергетикасы җайланмалары булу.

6. Арбитраж суды тарафыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылган очракта, алар (авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) бу хакта эш кузгатылган көнне Министрлыкка хәбәр итәргә тиеш.

Субсидияләр аларга карата арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелми.

7. Субсидияләр бирелүнең нәтиҗәлелек күрсәткечләре булып төзелгән һәм модернизацияләнгән теплица комплексларында проект куәтенә ирешү тора.

8. Субсидияләр субсидия бирелгән елдан соң 2 елдан да артмаган чорда төзелә һәм (яки) модернизацияләнә башлаган теплица комплексларын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен, – өстәлгән бәясеннән салымын һәм проект-эзләнү эшләренә тотылган чыгымнарны алып, смета бәясеннән 20 проценты күләмендә, ләкин объектның чик күләмендәге бәясеннән артык булмаган күләмлш бирелә.

Объектның чик күләмендәге бәясе объектның куәт берәмлеге бәясенең Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы билгели торган чик күләмдәге күрсәткеченнән чыгып билгеләнә.

Турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау объектны кабул итү Акты тапшырылганнан соң башкарыла.

Техника һәм җайланма өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча федераль бюджеттан алына торган акчаларның өлеше техника һәм (яки) җайланма берәмлеге бәясенең 20 процентын тәшкил итә (ләкин объектның смета бәясенең 5 проценттыннан да артык түгел).

9. Субсидияләрне алу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

ирекле рәвештә, үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирелү турында гариза;

төзү һәм модернизацияләү буенча җыелма смета исәпләмәсенең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

проект документларының һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең дәүләт экспертизасы буенча уңай бәяләмәсенең һәм смета бәясен билгеләүнең дөреслегенә карата үткәрелгән дәүләт экспертизасының авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

объект төзелешенә бирелгән рөхсәтнең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәсе;

саклыкханәләрне төзүгә һәм моңернизацияләүгә карата подряд шартнамәләренең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ КС-2 "Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт" статистика рәвеше буенча белешмәләрнең төзелеш контрольлеген башкаручы оешма белән килештерелгән, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ КС-3 "Башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында акт" статистика рәвеше буенча белешмәләрнең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ КС-2 "Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт" статистика рәвеше буенча белешмәләрнең төзелеш контрольлеген башкаручы оешма белән килештерелгән һәм №КС-3 "Башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында акт" статистика рәвеше буенча белешмәләрнең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре, эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда;

№КС-11 "Төзелеше тәмамланган объектны кабул итү акты" статистика рәвеше буенча актларның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ ОС-1а "Бинаны (корылманы) кабул итү-тапшыру турында" һәм №ОС-3 "Үзгәртеп корылган, модернизацияләнгән төп чара объектларын кабул итү-тапшыру актлары" статистика рәвешләре буенча актларның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ОС-15 "Җайланманы монтажлауга кабул итү-тапшыру турында акт" статистика рәвеше буенча актларның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең милегендә төзелгән һәм (яки) модернизацияләнгән саклыкханәләр булуны раслый торган документларның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

субсидия бирелгән елдан соң 2 елдан иртәрәк булмаган чорда сатып алынган техниканы һәм җайланманы китерү (сату-алу) шартнамәсенең, товар кәгазенең, счет-фактураның, китертү (сату-алу) шартнамәсенә карата кабул итү-тапшыру актының, ОС-1 рәвеше буенча кабул итү-тапшыру актының авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

банк тарафыннан таныкланган, техника һәм җайланма өчен түләнәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләре;

җайланманың яисә техниканың паспорты күчермәсе (эшләнмә паспорты);

Министрлык раслаган рәвештә субсидияләр бирү өчен белешмә-исәпләмә.

10. Министрлык:

субсидияләр бирелү турында гаризаны кергән көнендә дәфтәрдә терки, ул номерланырга, тегелергә һәм мөһер белән беркетелергә тиеш;

гаризаны теркәгәннән соң 20 көнлек чорда тапшырылган документларның шушы Тәртипнең 9 пунктына туры килүе буенча тикшерә һәм субсидияне бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

Субсидия бирүдән баш тарту нигезләре:

документларны тулы күләмдә тапшырмау яки аларның шушы Тәртип таләпләренә җавап бирмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитында калдык өлеш булмау.

Субсидияләрне бирүдән баш тарткан очракта, Министрлык шушы пунктның өченче кызыл юлында күрсәтелгән чор узганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек чорда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә баш тарту турында белдерүнамә җибәрә.

Субсидия бирүдән баш тарту законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять кылынырга мөмкин.

11. Министрлык авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән Министрлык раслаган рәвештә һәм чорларда субсидияләр бирү турында килешү төзи.

12. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең исәп-хисап счетларына, акча чараларын бирү турында карар кабул ителгәннән соң 10 эш көне эчендә, Министрлык раслаган белешмә-исәпләмәләр нигезендә, акча чараларын күчерүне хәл итә.

13. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.

14. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.

15. Бу Тәртипнең 13 һәм 14 пунктларында күрсәтелгән бюджет акчаларын федераль бюджет кеременә ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

16. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

17. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның җитәкчеләренә һәм вазифаи затларына йөкләнә.

18. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
21.03.2016 №45/2-пр боерыгына
4 кушымта

2016 елда федераль бюджет акчалары хисабыннан сөт юнәлешендәге терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр бирү
ТӘРТИБЕ

1. Бу Тәртип 2016 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы гражданнардан кала, (алга таба – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) һәм Россия оешмаларына федераль бюджет акчалары хисабыннан сөт юнәлешендәге терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә, шулай ук техника һәм җайланма сатып алуга турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

Бу Кагыйдәләрдә техника һәм җайланма дигәндә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 27 декабрендәге “Авыл хуҗалыгы техникасын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында” № 1432 карары белән расланган Авыл хуҗалыгы техникасын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү кагыйдәләрендәге таләпләргә җавап бирә торган авыл хуҗалыгы техникасы аңлашыла.

2. Субсидияләрне бирүнең максаты булып Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2015 елның 24 июлендәге “Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә юнәлдерелгән инвестиция проектларын сайлап алу тәртибен раслау турында” № 318 боерыгында билгеләнгән теплица комплекслары куәтләрен төзүгә һәм (яки) аларны модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау тора.

3. Субсидияләрне бирү Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) шушы Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга расланган бюджет йөкләмәләре чикләрендә башкарыла.

4. Субсидияләр алуга карата авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен сайлап алу критерийлары:

а) сөт юнәлешендәге терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә турыдан-туры тоткан чыгымнарның бер өлешен каплау:

төп эшчәнлек төре – авыл хуҗалыгында җитештерү, сөт юнәлешендә мөгезле эре терлек һәм (яки) кәҗәләр үрчетү;

төзелгән, сөт юнәлешендәге, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең милегендә булган кимендә 400 баш сыерга һәм (яки) кимендә 100 баш кәҗәгә исәпләнгән терлекчелек комплекслары (сөт фермалары) булу;

б) сөт юнәлешендәге терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау:

төп эшчәнлек төре – авыл хуҗалыгында җитештерү, сөт юнәлешендәге мөгезле эре терлек һәм (яки) кәҗәләр үрчетү;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрендә милекчелек хокукында куәте кимендә 200 баш сыерга һәм (яки) кимендә 100 баш ана кәҗәгә исәпләнгән, модернизацияләнгән сөт юнәлешендәге терлекчелек комплекслары (сөт фермалары) булу.

5. Төзелгән һәм (яки) модернизацияләнгән сөт юнәлешендәге терлекчелек комплекслары (сөт фермалары) билгеләнгән проект куәтеннән 100 процент күләмендә, чыгу-рөхсәт бирү документлары һәм тоташтыруның техник шартлары расланган җылылык, энергия һәм су ресурслары белән тәэмин ителергә тиеш.

6. Шушы Тәртип нигезендә субсидия алу максатларында сөт юнәлешендәге терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) модернизацияләү, түбәндәге юнәлеш кысаларында барлык чаралар үтәлү шарты белән, әлеге юнәлешләрнең икесенең берсе буенча башкарылырга тиеш:

а) терлек асрау, сөт саву, сөтне кабул итү һәм (яки) беренчел эшкәртү системалары җайланмаларын модернизацияләү;

сөт сава торган җайланманы җиһазлау һәм (яки) алмаштыру;

сөт продуктларын салкында эшкәртүне һәм саклауны исәпкә алып, сөтне кабул итү һәм (яки) беренчел эшкәртү буенча җайланманы җиһазлау һәм (яки) алмаштыру;

асрауның яңа технологиясе өчен бинаның планын үзгәртү;

б) терлек азыгы җитештерү һәм тирес түгү өчен җайланманы модернизацияләү:

терлек азыгын әзерләү һәм тарату өчен җайланманы җиһазлау һәм (яки) алмаштыру;

тирес чыгару өчен җайланманы җиһазлау һәм (яки) алмаштыру.

7. Арбитраж суды тарафыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылган очракта, алар (авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) бу хакта эш кузгатылган көнне Министрлыкка хәбәр итәргә тиеш.

Субсидияләр аларга карата арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелми.

8. Субсидияләр бирелүнең нәтиҗәлелек күрсәткечләре:

төзелгән һәм модернизацияләнгән сөт юнәлешендәге терлекчелек комплексларында (сөт фермаларында) сөт җитештерү буенча проект куәтенә ирешү;

төзелгән һәм модернизацияләнгән сөт юнәлешендәге терлекчелек комплексларында (сөт фермаларында) планлаштырылган сөт продуктлылыгы дәрәҗәсе елына бер сыерга кимендә 6000 кг – аларны файдалануга тапшырганнан соң 2 елдан соңга калмыйча.

9. Субсидияләр субсидия бирелгән елдан соң 2 елдан да артмаган чорда төзелә һәм (яки) модернизацияләнә башлаган сөт юнәлешендәге терлекчелек комплексларын (сөт фермаларын) төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен, – өстәлгән бәясеннән салымын һәм проект-эзләнү эшләренә тотылган чыгымнарны алып, смета бәясеннән 20 проценты күләмендә, ләкин объектның чик күләмендәге бәясеннән артык булмаган күләмлш бирелә.

Объектның чик күләмендәге бәясе объектның куәт берәмлеге бәясенең Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы билгели торган чик күләмдәге күрсәткеченнән чыгып билгеләнә.

Турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау объектны кабул итү Акты тапшырылганнан соң башкарыла.

Техника һәм җайланма өчен турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча федераль бюджеттан алына торган акчаларның өлеше техника һәм (яки) җайланма бәрәмлеге бәясенең 20 процентын тәшкил итә (ләкин объектның смета бәясенең 5 процентлыннан да артык түгел).

10. Субсидияләрне алу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

ирекле рәвештә, үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирелү турында гариза;

төзү һәм модернизацияләү буенча җыелма смета исәпләмәсенең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

проект документларының һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең дәүләт экспертизасы буенча уңай бәяләмәсенең һәм смета бәясен билгеләүнең дөреслегенә карата үткәрелгән дәүләт экспертизасының авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

объект төзелешенә бирелгән рөхсәтнең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәсе;

саклыкханәләрне төзүгә һәм модернизацияләүгә карата подряд шартнамәләренең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ КС-2 "Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт" статистика рәвеше буенча белешмәләрнең төзелеш контрольлеген башкаручы оешма белән килештерелгән, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ КС-3 "Башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында акт" статистика рәвеше буенча белешмәләрнең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ КС-2 "Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт" статистика рәвеше буенча белешмәләрнең төзелеш контрольлеген башкаручы оешма белән килештерелгән һәм №КС-3 "Башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында акт" статистика рәвеше буенча белешмәләрнең авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре, эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда;

№КС-11 "Төзелеше тәмамланган объектны кабул итү акты" статистика рәвеше буенча актларның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ ОС-1а "Бинаны (корылманы) кабул итү-тапшыру турында" һәм №ОС-3 "Үзгәртеп корылган, модернизацияләнгән төп чара объектларын кабул итү-тапшыру актлары" статистика рәвешләре буенча актларның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

№ОС-15 "Җайланманы монтажлауга кабул итү-тапшыру турында акт" статистика рәвеше буенча актларның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең милегендә төзелгән һәм (яки) модернизацияләнгән саклыкханәләр булуны раслый торган документларның авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

субсидия бирелгән елдан соң 2 елдан иртәрәк булмаган чорда сатып алынган техниканы һәм җайланманы китерү (сату-алу) шартнамәсенең, товар кәгазенең, счет-фактураның, китертү (сату-алу) шартнамәсенә карата кабул итү-тапшыру актының, ОС-1 рәвеше буенча кабул итү-тапшыру актының авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан таныкланган күчермәләре;

банк тарафыннан таныкланган, техника һәм җайланма өчен түләнәнлекне раслый торган түләү йөкләмәләре;

җайланманың яисә техниканың паспорты күчермәсе (эшләнмә паспорты);

Министрлык раслаган рәвештә субсидияләр бирү өчен белешмә-исәпләмә.

11. Министрлык:

субсидияләр бирелү турында гаризаны кергән көнендә дәфтәрдә терки, ул номерланырга, тегелергә һәм мөһер белән беркетелергә тиеш;

гаризаны теркәгәннән соң 20 көнлек чорда тапшырылган документларның шушы Тәртипнең 9 пунктына туры килүе буенча тикшерә һәм субсидияне бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

Субсидия бирүдән баш тарту нигезләре:

документларны тулы күләмдә тапшырмау яки аларның шушы Тәртип таләпләренә җавап бирмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитында калдык өлеш булмау.

Субсидияләрне бирүдән баш тарткан очракта, Министрлык шушы пунктның өченче кызыл юлында күрсәтелгән чор узганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек чорда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә баш тарту турында белдерүнамә җибәрә.

Субсидия бирүдән баш тарту законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять кылынырга мөмкин.

12. Министрлык авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән Министрлык раслаган рәвештә һәм чорларда субсидияләр бирү турында килешү төзи.

13. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең исәп-хисап счетларына, шушы Тәртинең 11 пунктындагы өченче кызыл юлда күрсәтелгән чор узганнан соң биш көнле чорда Министрлык раслаган белешмә-исәпләмәләр нигезендә, акча чараларын күчерүне хәл итә.

14. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.

16. Бу Тәртипнең 14 һәм 15 пунктларында күрсәтелгән бюджет акчаларын федераль бюджет керемәнә ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

17. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын,

максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

18. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның җитәкчеләренә һәм вазифаи затларына йөкләнә.

19. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.